**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАРЫ

№ 4 7 ноябрь 2022 ел.

**"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Түбән Баланда авылында гражданнар җыенын билгеләү: үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 18 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Түбән Баланда авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлегенең Түбән Баланда авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә: ТР, Аксубай муниципаль районы, Түбән Баланда авылы, Зеленая урамы, 12 йорт
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлегенең Түбән Баланда авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү : I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Хәрби хезмәтенең сроклы хезмәтендәге хәрбиләрдән, Украинада спецоперациядә катнашырга мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

**Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Түбән Баланда авылы урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) Т
- Түбән Баланда авылы территориясендә үсентеләр чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу).
- Трактор трейлерын сатып алу.

**Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру**

- Тирәнлектәге насосны ремонтлау һәм алыштыру, суүткәргечне ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) Түбән Баланда авылында .

**Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

- Түбән Баланда авылында Толстой урамында, Ленин урамында, Терешковой урамында таш алу, ташу, җәю, вак ташны тигезләү, ком һәм грунттан нигез салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)..
- Кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү) Түбән Баланда авылында.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы С.С.Елисеев